РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОЗЮРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная 1А село Старые Зюри , 422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
E-mail: Szur.Tul @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1А, Иске Җөри авылы,422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
**E-mail: Szur.Tul @tatar.ru**

ОКПО 94318056 ОГРН 1061675010429 ИНН/КПП 1619004404/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№17**

**КАРАР**
**«13»августа 2020 г.**

**Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитеты карары проекты**

Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Иске Җөри авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Иске Җөри авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Иске Җөри авылы, Мәктәп урамы, Мәктәп бинасы янында мәгълүмат стенды;
- Иске Җөри авылы, Мәктәп урамы, Фельдшер акушерлык бинасы янында мәгълүмат стенды;
- Олы Тиләҗе авылы,Үзәк урамы, Клуб бинасы янында мәгълүмат стенды;

- Оремширмә авылы, Югары урамы,  Фельдшер акушерлык  бинасы янында мәгълүмат стенды;

- Караширмә авылы, Зур юл урамы,  ,  шәхси эшмәкәр “Гильмуллин” кибет янында мәгълүмат стенды.

2. Иске Җөри  авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында»  2019 елның 25 июль № 25  карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Иске Җөри авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча :  Иске Җөри авылы, Мәктәп урамы, 1 А йорт,  Иске Җөри авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында  урнаштырырга.

Р.Р.Мараков